| | |
|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.02.2023 Баулы шәһәре № 160

2023 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә 2023 елга Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе И.И. Гозәеров

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Советының 2023 елның
2 февралендәге 160 номерлы
карарына
1 нче кушымта

2023 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы)

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнде.

1.2. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Баулы муниципаль районы мөлкәте структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. Баулы муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. 2022 елга Баулы муниципаль районын хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертелгән, ләкин хосусыйлаштыру үткәрелмәгән объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектәге муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен 2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. 2023 елда хосусыйлаштыруның фараз планы гамәлдә булган чорда хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль мөлкәт исемлеге яңа күчемсез милек объектлары белән тулыландырырга мөмкин.

2.5. 2023 елда түбәндәге муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш (1 нче таблица).

1 нче таблица

| № п/п | Объект исеме | Урнашу урыны (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы) |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Гараж бинасы, 16:55:010104:1322:0123, S- 340,9 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, ОРС гаражы |
| 2. | Җир участогы, 16:55:010104:1322, S- 2766,0 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, ОРС гаражы |
| 3 | Торак булмаган бина - запас частьләр склады,кадастр номеры 16:55:010308:56, гомуми мәйданы 466,6 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |
| 4 | Гомуми мәйданы 24 970,0 кв.м җир участогы, кадастр номеры 16:55:010308:69 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |